СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-39 от «30» июня 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең
Генераль планы турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Премьер – министры А.В.Песошин белән килештерелгән Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Генераль планы проектына 2020 елның 16 январендәге бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Генераль планын әлеге карарга кушымталар нигезендә расларга.

2. Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Генераль планын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының интернет челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А. П. Иванов

000028